**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КҮГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**30 нчы декабрь 2015 ел** **№ 27**

Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

12.06.2002 Федераль законның 15 статьясы нигезендә № 67-ФЗ "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында", "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында" 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Зеленодольск муниципаль районы "Күгеш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 10 һәм 83 статьялары, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, Күгеш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Җирле референдум үткәрүне оештыру турында» 2015 елның 28 декабрендәге 12 номерлы карары, Күгеш авыл җирлеге Советының «Җирле референдумны үткәрү инициативасы турында» гы 28 декабрендәге 24 номерлы карары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге Советы карар **кабул итте**:

1. 2016 елның 6 мартына Яшел Үзән муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2016 елда Күгеш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым акчасын кертүгә һәм алган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

| № | Гражданнарның үзара салым акчаларын тоту юнәлеше | Гражданнарның үзара салым акчаларын тоту күләме (сум) |
|---|---|---|
| 1. | Янгынга каршы су белән тәэмин итү объектларын һәм чыганакларын (пирслар, краннар, гидрантлар, ясалма сулыклар, сулыкларга керү юллары) төзү, агымдагы һәм капиталь ремонтлау | 37500= |
| 2. | Автомобиль юлларын, ишегалды территорияләрен, кварталара юлларны төзү, агымдагы һәм капиталь ремонтлау, карап тоту | 109500= |

«ӘЙЕ”                                   “ЮК”

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru.), Күгеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Күгеш авылы, Совет урамы, 11 нче йорт (администрация бинасы) һәм Күгеш авылы, Совет урамы, 17 нче йорт (мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча халыкка җиткерелергә тиеш

**Күгеш авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе**                                        **А.А.Гатауллин**

.